**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Ш.Марджани, дом 6

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Ш.Мәрҗани урамы, 6нчы йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«31» гыйнвар 2025 ел. № 29

**Әтнә муниципаль районында 2025 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортта торак урыннары хуҗалары өчен торак бинаны тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын раслау турында.**

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 маддәсенең 4 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2018 елның 06 апрелендәге 213/пр номерлы «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннары хуҗалары өчен торак бинаны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү буенча методик киңәшләрне раслау, торак урынын карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү турында»гы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты карар чыгара:

1. 2025 елга Әтнә муниципаль районында күп фатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак биналар хуҗалары өчен торак бинаны тоту өчен түләү күләменең чик индексын 9 % күләмендә расларга.

2. Әлеге карар 01.01.2025 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (http://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әтнә район башкарма комитеты урынбасары М. Л. Халиковка йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Каюмов